| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 август 2022 ел № 140

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә тышкы реклама чараларын һәм мәгълүмат урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы, ««Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль законнарга туры китереп һәм Татарстан Республикасы буенча монополиягә каршы федераль хезмәт идарәсенең П06-32/2022 номерлы кисәтүе һәм Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Балтач район Советы карар бирде:

1. Балтач район Советының 2021 елның 15 мартындагы 42 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә тышкы реклама чараларын һәм мәгълүмат урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7.1 – 7.17 пунктларны төшереп калдырырга;

1.2. Нигезләмәнең 8 бүлегендәге 8.5 пунктта «юридик зат яки шәхси эшкуар» сүзтезмәсеннән соң «яисә үзмәшгуль» сүзтезмәсен өстәргә;

1.3. Нигезләмәнең 8 бүлегендәге 8.7 пунктның 5 абзацында «Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры» сүзеннән соң «, үзмәшгульләр өчен - исәпкә кую турында белешмә» сүзтезмәсен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач районы Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин